ГЛАВА ЯНУРУСОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
САРМАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САРМАН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ЯНУРЫС АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
14.08.2023

КАРАР
№ 3

«Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Янурыс авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында» карар проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләү хакында

«Россия Федерациясендә тимер юл транспорты турында» 2003 елның 10 гыйнварындагы 17-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Янурыс авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына, ЯНУРЫС авыл җирлегенең 2021 елның 29 декабрендәге 18 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Янурыс авыл җирлегендә гавами тыңлауларны оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы нигезләмәгә таянып, карар чыгарды:

1. Әлегеypарга кушымта нигезендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Янурыс авыл җирлеге Советының 2022 елның 25 ноябрендәге 20 номерлы карары белән расланган «Янурыс авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында» проект буенча гавами тыңлаулар билгеләргә.

2. Билгеләргә:

- гавами тыңлауларны оештыручы - «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Янурыс авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында» проектын әзерләү комиссиясе - үткәрү датасы һәм вакыты - 2023 елның 24 августы 14.00 сәгатьтә;

- үткәрелү урыны – Янурыс авылы, Ленин урамы, 43в бинасындагы тамашалар залында;

- язма тәкъдимнәр һәм искәрмәләр Татарстан Республикасы Янурыс авылы, Ленин урамы, 43в йорт адресы буенча Сарман муниципаль районы

Янурыс авыл җирлеге башкарма комитетына кертелергә мөмкин,(эш көннәрендә 8.00 дән 16.00 сәгатькә кадәр (төшке ашка тәнәфес 12.00 сәгатьтән 13.00 сәгатькә кадәр).

3. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Янурыс авыл җтирлеге Советының 2022 елның 25 ноябрендәге 20 номерлы карары белән расланган «Янурыс авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында» проектын әзерләү комиссиясе:

- гамәлдәге законнар нигезендә һәм әлеге карар белән билгеләнгән срокларда Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Янурыс авыл җирлеге Советының 2022 елның 25 ноябрендәге 20 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Янурыс авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында» проекты буенча гавами тыңлаулар әзерләргә һәм уздырырга;

- гавами тыңлаулар уздыру нәтиҗәләре турында бәяләмә әзерләргә һәм аны билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга;

4. Башлыкның әлеге карарын Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Сарман муниципаль районының рәсми сайтында http/ sarmanovo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

«Сарман авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге
Башлыгы А.Ә.Мөхәммәдиева

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Янурыс авыл җирлеге башлыгының карарына 1 нче кушымта 10.08.2023 елның № 3

**Сарман муниципаль районының «Янурыс авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территорияләрен төзекләндерү кагыйдәләренә кертү турында**

1. 2 бүлекнең 4.1 пунктын төшереп калдырырга;
2. 3.6.1 пунктының «й» пунктчасында «тимер юллар,» сүзләрен төшереп калдырырга;
3. 3.7.2 пунктындагы «д» пунктчасында «һәм тимер юл» сүзләрен төшереп калдырырга;
4. 3 бүлекнең 3.11.8, 3.11.9, 3.11.10 пунктларында «(тимер юл)» сүзләрен төшереп калдырырга;
5. 4 бүлекнең 4.2.7 пунктын төшереп калдырырга.